**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Чирмешән авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең Кече Чегодай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 1 ноябрендәге 4 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең Кече Чегодай торак пунктында 2024 елда үзара салым кертү турында» 2023 елның 1 ноябрендәге 8 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең Кече Чегодай торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында.

27 март 2024 ел № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары (2023 елның 29 ноябрендәге №1532 редакциясендә) белән расланган үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Чирмешән авыл җирлеге» Уставы нигезендә гражданнар җыенына түбәндәге мәсьәлә чыгарылды:

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең Кече Чегодай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 1 ноябрендәге 4 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең Кече Чегодай торак пунктында 2024 елда үзара салым кертү турында» 2023 елның 1 ноябрендәге 8 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең Кече Чегодай торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү белән һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрү белән килешәсезме:

- **тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау** (урам яктырткычларын

монтажлау, ремонтлау, алыштыру, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);

**- торак пункт территориясен төзекләндерү** (җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү, Кече Чегодай торак пункты урамнарын карап тоту, үлән чабу, сабакларны, агачларны, төзелеш чүп-чарларын җыю, триммерлар алу, тракторны тоту, хезмәт күрсәтү чыгымнары, тракторчыга хезмәт хакы, ягулык-майлау материаллары, арба һәм махсус техника сатып алу, запас частьләр, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар алу.

**Гражданнар җыены карар кылды:**

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең Кече Чегодай торак пунктында халык җыены **булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.**

3. Киләсе карарны: «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең Кече Чегодай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 1 ноябрендәге 4 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең Кече Чегодай торак пунктында 2024 елда үзара салым кертү турында» 2023 елның 1 ноябрендәге 8 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең Кече Чегодай торак пунктында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында» түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә:

**- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау** (урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алыштыру, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);

**- торак пункт территориясен төзекләндерү** (җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү, Кече Чегодай торак пункты урамнарын карап тоту, үлән чабу, сабакларны, агачларны, төзелеш чүп-чарларын җыю, триммерлар алу, тракторны тоту, хезмәт күрсәтү чыгымнары, тракторчыга хезмәт хакы, ягулык-майлау материаллары, арба һәм махсус техника сатып алу, запас частьләр, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар алу **кабул ителгән дип танырга.**

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам

Халык җыенында рәислек итүче
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе М.Д.Шәйхетдинов